**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**О внесении изменений в отдельные указы Президента Республики Татарстан**

1. Внести в состав Комитета по присуждению Международной Арбузовской премии в области фосфорорганической химии при Президенте Республики Татарстан (далее – Комитет), утвержденный Указом Президента Республики Татарстан от 18 августа 2006 года № УП-313 «Об утверждении состава Комитета по присуждению Международной Арбузовской премии в области фосфорорганической химии при Президенте Республики Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 25 сентября 2013 года № УП-929, от 20 декабря 2014 года № УП-1160, от 8 апреля 2017 года № УП-297 и от 28 марта 2019 года № УП-186), следующие изменения:

а) вывести из состава Комитета Э.С. Батыеву, Р.Т. Бурганова, В.И. Галкина, А.И. Коновалова, С.В. Юшко;

б) ввести в состав Комитета:

Казакова Юрия Михайловича – временно исполняющего обязанности ректора федерального государственного бюджетного образовательного учреждения высшего образования «Казанский национальный исследовательский технологический университет», доктора технических наук (по согласованию);

Хадиуллина Ильсура Гараевича – министра образования и науки Республики Татарстан;

Яхварова Дмитрия Григорьевича – заведующего лабораторией, главного научного сотрудника Института органической и физической химии им. А.Е. Арбузова – обособленного структурного подразделения федерального государственного бюджетного учреждения науки «Федеральный исследовательский центр «Казанский научный центр Российской академии наук», профессора Российской академии наук, доктора химических наук (по согласованию);

в) изложить в следующей редакции наименования должностей членов Комитета:

И.С. Антипина – «профессор кафедры органической и медицинской химии Химического института им. А.М. Бутлерова федерального государственного автономного образовательного учреждения высшего образования «Казанский (Приволжский) федеральный университет», член-

корреспондент Российской академии наук, доктор химических наук (по согласованию)»;

О.Г. Синяшина – «заместитель академика-секретаря отделения химии и наук о материалах Российской академии наук, руководитель научного направления «Химия» федерального государственного бюджетного учреждения науки «Федеральный исследовательский центр «Казанский научный центр Российской академии наук», академик Российской академии наук, заместитель председателя Комитета (по согласованию)».

2. Внести в состав Комитета по присуждению Государственной премии Республики Татарстан имени В.Е. Алемасова (далее – Комитет), утвержденный Указом Президента Республики Татарстан от 22 сентября 2014 года № УП-913 «Об учреждении Государственной премии Республики Татарстан имени В.Е. Алемасова» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 22 февраля 2016 года № УП-200, от 13 апреля 2018 года № УП-309 и от 29 января 2020 года № УП-41), следующие изменения:

а) вывести из состава Комитета Р.Т. Бурганова, А.Н. Карпова;

б) ввести в состав Комитета:

Подоксика Вячеслава Григорьевича – заместителя генерального директора – технического директора акционерного общества «Зеленодольский завод имени А.М. Горького» (по согласованию);

Хайруллина Рамиля Камилевича – заместителя министра образования и науки Республики Татарстан;

в) изложить в следующей редакции наименования должностей членов Комитета:

А.Х. Гильмутдинова – «помощник Президента Республики Татарстан, академик Академии наук Республики Татарстан, профессор, доктор физико-математических наук, заместитель председателя Комитета»;

Б.И. Найшулера – «заместитель директора филиала по конструированию и технологиям – директор Инженерного центра Казанского авиационного завода им. С.П. Горбунова – филиала публичного акционерного общества «Туполев» (по согласованию)».

3. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 1 ноября 2014 года № УП-1014 «Об учреждении Международной премии имени А.Н. Туполева за выдающийся вклад в области инженерных наук» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 22 февраля 2016 года № УП-200, от 9 июня 2017 года № УП-488 и от 13 апреля 2018 года № УП-309) следующие изменения:

а) в пункте 7 Положения о Международной премии имени А.Н. Туполева за выдающийся вклад в области инженерных наук слова «организациями высшего образования» заменить словами «образовательными организациями высшего образования»;

б) в Положении о Комитете по присуждению Международной премии имени А.Н. Туполева за выдающийся вклад в области инженерных наук:

пункт 3 изложить в следующей редакции:

«3. В состав Комитета включаются представители государственных органов, российских и иностранных образовательных организаций высшего образования, научных и иных организаций.»;

в пункте 5 слова «организации высшего образования» заменить словами «образовательные организации высшего образования»;

в) в составе Комитета по присуждению Международной премии имени А.Н. Туполева за выдающийся вклад в области инженерных наук (далее – Комитет):

вывести из состава Комитета Р.Т. Бурганова, О.Г. Синяшина;

ввести в состав Комитета:

Калачева Алексея Алексеевича – исполняющего обязанности директора федерального государственного бюджетного учреждения науки «Федеральный исследовательский центр «Казанский научный центр Российской академии наук», профессора Российской академии наук, доктора физико-математических наук (по согласованию);

Хадиуллина Ильсура Гараевича – министра образования и науки Республики Татарстан;

изложить наименование должности А.Х. Гильмутдинова в следующей редакции: «помощник Президента Республики Татарстан, академик Академии наук Республики Татарстан, профессор, доктор физико-математических наук, заместитель председателя Комитета».

4. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
14 июля 2021 года
№ УП-579

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Фосфор органик химия өлкәсендә халыкара Арбузов премиясен бирү комитеты составын раслау турында» 2006 елның 18 августындагы ПУ-313 Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 25 сентябрендәге ПУ-929 номерлы, 2014 елның 20 декабрендәге ПУ-1160 номерлы, 2017 елның 8 апрелендәге ПУ-297 номерлы һәм 2019 елның 28 мартындагы ПУ-186 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Фосфор органик химия өлкәсендә халыкара Арбузов премиясен бирү комитеты (алга таба – Комитет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комитет составыннан Э.С. Батыеваны, Р.Т. Борһановны, В.И. Галкинны, А.И. Коноваловны, С.В. Юшконы чыгарырга;

б) Комитет составына кертергә:

Казаков Юрий Михайловичны – «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры вазыйфаларын вакытлыча башкаручыны, техник фәннәр докторын (килешү буенча);

Һадиуллин Илсур Гәрәй улын – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрын;

Яхваров Дмитрий Григорьевичны – «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең аерымланган структур бүлекчәсе – А.Е. Арбузов исемендәге Органик һәм физик химия институты лабораториясе мөдирен, баш фәнни хезмәткәрен, Россия фәннәр академиясе профессорын, химия фәннәре докторын (килешү буенча);

в) Комитет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

И.С. Антипинның – «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе А.М. Бутлеров исемендәге Химия институтының органик һәм медицина химиясе кафедрасы профессоры, Россия фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы, химия фәннәре докторы (килешү буенча)»;

О.Г. Синяшинның – «Россия фәннәр академиясенең химия һәм материаллар турында фәннәр бүлекчәсе академик-секретаре урынбасары, «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең «Химия» юнәлеше фәнни җитәкчесе, Россия фәннәр академиясе академигы, Комитет рәисе урынбасары (килешү буенча)».

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен гамәлгә кую турында» 2014 елның 22 сентябрендәге ПУ-913 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 22 февралендәге ПУ-200 номерлы, 2018 елның 13 апрелендәге ПУ-309 номерлы һәм 2020 елның 29 гыйнварындагы ПУ-41 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты (алга таба – Комитет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комитет составыннан Р.Т. Борһановны, А.Н. Карповны чыгарырга;

б) Комитет составына кертергә:

Подоксик Вячеслав Григорьевичны – «Зеленодольскиның А.М. Горький исемендәге заводы» акционер җәмгыяте генераль директоры урынбасары – техник директорын (килешү буенча);

Хәйруллин Рамил Камил улын – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасарын;

в) Комитет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

А.Х. Гыйльметдиновның – «Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы, профессор, физика-математика фәннәре докторы, Комитет рәисе урынбасары»;

Б.И. Найшулерның – «Туполев» гавами акционер җәмгыяте филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводының Инженерлык үзәге директоры – филиал директорының конструкцияләр һәм технологияләр буенча урынбасары (килешү буенча)».

3. Татарстан Республикасы Президентының «Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премияне гамәлгә кую турында» 2014 елның 1 ноябрендәге ПУ-1014 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 22 февралендәге ПУ-200 номерлы, 2017 елның 9 июнендәге ПУ-488 номерлы һәм 2018 елның 13 апрелендәге ПУ-309 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премия турында нигезләмәнең 7 пунктында «югары белем бирү оешмалары» сүзләрен «югары белем бирү мәгариф оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

б) Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премияне бирү комитеты турында нигезләмәдә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Комитет составына дәүләт органнары, Россия һәм чит ил югары белем бирү мәгариф оешмалары, фәнни һәм башка оешмалар вәкилләре кертелә.»;

5 пунктта «югары белем бирү оешмалары» сүзләрен «югары белем бирү мәгариф оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

в) Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премияне бирү комитеты (алга таба – Комитет) составында:

Комитет составыннан Р.Т. Борһановны, О.Г. Синяшинны чыгарырга;

Комитет составына кертергә:

Калачев Алексей Алексеевичны – «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе директоры вазыйфаларын башкаручыны, Россия фәннәр академиясе профессорын, физика-математика фәннәре докторын (килешү буенча);

Һадиуллин Илсур Гәрәй улын – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрын;

А.Х. Гыйльметдиновның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы, профессор, физика-математика фәннәре докторы, Комитет рәисе урынбасары».

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2021 ел, 14 июль
№ ПУ-579